ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы законнары җыелмасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы законнары җыелмасы турында” 1999 елның 15 сентябрендәге 2355 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 10; 2004, № 3 (II өлеш); 2009, № 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендә “гамәлдәге” сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяда “рәсми басмаларда” сүзләрен “билгеләнгән тәртиптә” сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“**3 статья.** Законнар җыелмасына дәүләт, хезмәт, коммерция серен тәшкил итә торган, шулай ук вакытлыча төсмергә ия актлар кертелми.”;

4) 4 статьяның икенче өлешендә:
а) өченче абзацта “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы” сүзләрен “Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы” сүзләренә алмаштырырга;
б) дүртенче һәм бишенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;
в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“– Законнар җыелмасын әзерләү этапларын һәм срокларын билгели.”;

5) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**5 статья.** Законнар җыелмасының чираттагы томын әзерләүгә һәм бастырып чыгаруга бәйле агымдагы эшне гамәлгә ашыру өчен Республика комиссиясе каршында Татарстан Республикасы законнары җыелмасын әзерләү һәм бастырып чыгару буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы җитәкчесе рәислегендә эшче комиссия (алга таба – эшче комиссия) төзелә.

Эшче комиссия:

Законнар җыелмасы томын төзи;

Законнар җыелмасы томына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын эшкәртүне гамәлгә ашыра.

Эшче комиссия составы Республика комиссиясе тарафыннан раслана.”;

6) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**6 статья.** Законнар җыелмасы кәгазь чыганакларда һәм электрон рәвештә бастырып чыгарыла. Законнар җыелмасының электрон рәвеше “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органының рәсми сайтында урнаштырыла.”;

7) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**7 статья.** Законнар җыелмасын әзерләү һәм яңарту, бастырып чыгару эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.”;

8) 8 һәм 9 статьяларны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 93-ТРЗ